МИНИСТЕРСТВО
ЛЕСНОГО ХОЗЯЙСТВА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
УРМАН ХУҖАЛЫГЫ
МИНИСТРЛЫГЫ

ПРИКАЗ БОЕРЫК

07.03.2018 Казан ш. № 126-осн

Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгының 2013 елның 22 октябрендәге 571/5-осн номерлы боерыгы белән расланган Әлмәт урманчылыгы урман хуҗалыгы регламентына үзгәрешләр кертү турында

Әлмәт урманчылыгы чикләрендә урманнарны тәртипкә китерү барышында ачыкланган урманнарның структурасы һәм торышы үзгәрүгә бәйле рәвештә, Россия Федерациясе Табигать ресурслары һәм экология министрлыгының 2017 елның 27 февралендәге 72 номерлы боерыгы белән расланган Урман хуҗалыгы реглмаментлары составы, аларны эшләү тәртибе, аларның гамәлдә булу чорлары һәм аларга үзгәрешләр кертү тәртибенең 16 пунктының 1 пунктчасы нигезендә боерык бирәм:

1. Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгының 2013 елның 22 октябрендәге 571/5-осн номерлы боерыгы белән расланган Әлмәт урманчылыгы урман хуҗалыгы регламентына, кушымтада бирелгән яңа редакциядә бәян итеп, үзгәрешләр кертергә.

2. Юридик бүлеккә әлеге боерыкны дәүләт теркәвенә алу һәм Татарстан Республикасы Хокукый мәгълүматының рәсми сайтында (PRAVO.TATARSTAN.RU) рәсми рәвештә бастырып чыгару өчен Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына җибәрергә.

3. Мәгълүмат технологияләрен үстерү секторына әлеге боерыкның теркәүгә алынуын һәм бастырып чыгарылуын техник яктан тәэмин итәргә.

4. Финанслар, бухгалтерия исәбенә алу һәм тикшереп тору бүлегенә әлеге боерыкның татар теленә тәрҗемә ителүенә бәйле чыгымнарның финанслануын тәэмин итәргә.

5. Бу Боерык үтәлешен контрольдә тотуны министрның беренче урынбасары Ә.Н.Бәдретдиновка йөкләргә.

Министр Р.А.Кузюров